КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 1 сентябрь г.Казань № 767

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларының, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектларының торышына, карап тотуга, сакланышына, кулланылышына, популярлаштыруына һәм сакланышына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 ноябрь, 863 нче; 2018 ел, 18 декабрь, 1170 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта татар текстында «төбәк дәүләт күзәтчелеген» сүзләреннән соң «һәм инвалидлар өчен мәдәни мирас объектларыннан файдалану шартларын тәэмин итүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $6^1$ – $6^2$ нче пунктлар өстәргә:

«$6^1$. Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге риск-юнәлешле алым кулланып гамәлгә ашырыла.

Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда риск-юнәлешле алымны куллану максатларында юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең эшчәнлеге бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән, мәҗбүри таләпләрне үтәмәүнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләрен, мәдәни мирас объектларына йогынты ясау дәрәҗәсен һәм мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималын исәпкә ала торган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген һәм һәм инвалидлар өчен мәдәни мирас объектларыннан файдалану шартларын тәэмин итүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештырганда юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген риск категориясенә кертү критерийлары (алга таба – Критерийлар) нигезендә рискның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

Юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең эшчәнлеген рискның билгеле бер категориясенә кертү турындагы карар, шулай ук риск категориясенә үзгәреш кертү турындагы карар дәүләт органы боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Дәүләт органының билгеле бер риск категориясенә кертү турындагы хокукый акты булмаганда, юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең эшчәнлеге түбән рисктагы категориягә кертелгән дип санала.

$6^2$. Юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлегенең риск категориясе җыелган баллар саны буенча аларны Критерийларның 1.1, 1.2 нче пунктларда каралган күрсәткечләргә кушу юлы белән билгеләнә.

Риск категориясен билгеләү:

10 баллдан һәм югарырак – югары рисктагы категория;

8 баллдан 10 баллга кадәр – шактый рисктагы категория;

6 баллдан 8 баллга кадәр – урта рисктагы категория;

4 баллдан 6 баллга кадәр – уртача рисктагы категория;

3 баллга кадәр – түбән рисктагы категория.

Юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне план буенча тикшерүләр үткәрү вакыты аларның эшчәнлегенең билгеле бер риск категориясенә каравын исәпкә алып билгеләнә.

Юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә карата план буенча тикшерүләр үткәрү, мондый затка бирелгән риск категориясенә карап, түбәндәге вакытларда гамәлгә ашырыла:

югары рисктагы категория өчен – ике елга бер тапкыр;

шактый рисктагы категория өчен – өч елга бер тапкыр;

урта рисктагы категория өчен – 4 елга 1 тапкырдан артмаган һәм 5 елга кимендә 1 тапкыр;

уртача рисктагы категория өчен – 6 елга 1 тапкырдан артмаган һәм 8 елга кимендә 1 тапкыр;

түбән рисктагы категориягә карата план буенча тикшерүләр үткәрелми.»;

түбәндәге эчтәлекле 16 – 20 нче пунктлар өстәргә:

«16. Дәүләт органы эшчәнлекләренә карата риск категориясе бирелгән юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр исемлеген (алга таба – исемлек) электрон формада алып бара.

Юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр исемлегенә кертү дәүләт органының юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген риск категориясенә кертү турындагы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген рискның төрле категорияләренә кертергә мөмкинлек бирә торган критерийлар булганда, юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген рискның иң югары категориясенә кертә торган критерийлар кулланылырга тиеш.

Исемлектә түбәндәге мәгълүмат бирелә:

юридик затның тулы исеме, индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) ;

төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең индивидуаль номеры;

мәдәни мирас объектының урнашу урыны / юридик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең фактта эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны;

бирелгән риск категориясе, шулай ук юридик затны яки индивидуаль эшмәкәрне билгеле бер риск категориясенә кертү турындагы боерыкның реквизитлары (датасы һәм номеры).

17. Исемлеккә кертелгән юридик затларның яки индивидуаль эшмәкәрләрнең дәүләт карары нигезендә югары һәм шактый рисктагы категориягә кертелгән эшчәнлеге турындагы мәгълүмат дәүләт органының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла һәм актуаль хәлдә тотыла.

Әлеге мәгълүматны урнаштыру Россия Федерациясенең дәүләт серен саклау турындагы законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

18. Эшчәнлеге риск категорияләренең берсенә кертелгән юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр соравы буенча дәүләт органы мондый сорау кергән көннән 15 эш көненнән дә артмаган вакытта аңа аларның эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында мәгълүмат, шулай ук аның эшчәнлеген билгеле бер риск категориясенә керткәндә файдаланылган белешмәләр бирә.

19. Юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр дәүләт органына аның эшчәнлегенә элегрәк бирелгән риск категориясе үзгәрү турында гариза (алга таба – гариза) бирергә хокуклы.

Гаризада түбәндәге мәгълүматлар бирелә:

юридик затның тулы исеме, индивидуаль эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда) ;

төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;

юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлегенә элек бирелгән риск категориясе турында мәгълүмат;

юридик затның адресы, индивидуаль эшмәкәрнең яшәү урыны адресы (кирәк булганда элемтә өчен башка почта адресы), телефоны һәм электрон почта адресы (булганда).

Гаризага юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлегенең гариза бирүче бирү өчен дәгъва итә торган мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген оештырганда юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген риск категориясенә кертү критерийларына туры килүе турында документлар теркәлә.

Дәүләт органы гаризаны карап тикшерә, юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр тарафыннан тапшырылган һәм аның карамагында булган документларны бәяли һәм аларны карап тикшерү йомгаклары буенча мондый гаризаны алган көннән 15 эш көненнән дә артмаган вакытта түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

гаризаны канәгатьләндерү һәм риск категориясен үзгәртү;

гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту.

20. Дәүләт органы гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар кабул ителгән көннән 3 эш көне эчендә юридик затка яки индивидуаль эшмәкәргә кабул ителгән карар турында гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча яки вәкаләтле вазыйфаи затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, юридик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең электрон почтасы адресы буенча (әгәр дә мондый адрес шул ук эзлеклелектә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында булса йә алар тарафыннан дәүләт органына элегрәк тапшырылган булса) тиешле хәбәрнамә җибәрү юлы белән хәбәр ителә.

Гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә юридик затка яки индивидуаль эшмәкәргә баш тартуның сәбәпләре турында хәбәр ителергә тиеш.

Дәүләт органы тарафыннан кабул ителгән гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турындагы карар белән килешмәгән очракта, юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр мондый карарга карата административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

әлеге Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген һәм һәм инвалидлар өчен мәдәни мирас объектларыннан файдалану шартларын тәэмин итүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештырганда юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр эшчәнлеген риск категориясенә кертү критерийлары

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Критерийлар | Крите-рийның мәгънәсе |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1.1. | Юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлегенең мәдәни мирас объектына, ачыкланган мәдәни мирас объектына, археологик мирас объектына, җир кишәрлегенә йогынтысы дәрәҗәсен бәяләү | 1.1.1. Мәдәни мирас объекты, ачыкланган мәдәни мирас объекты, археологик мирас объекты, җир кишәрлеге булу: | Х |
| | | милектә / файдалануда | 1 балл |
| | | «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихый һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30, 36 статьяларында каралган эшләр төрләре йогынтысы ясалырга тиешле җир кишәрлеге чикләрендә | 1 балл |
| | | 1.1.2. Мәдәни мирас объекты, ачыкланган мәдәни мирас объекты, археологик мирас объекты, җир кишәрлеге торышы | Х |
| | | авария хәлендә | 5 балл |
| | | канәгатьләндермәслек | 4 балл |
| | | канәгатьләндерерлек | 0 балл |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | 1.1.3. Саклау йөкләмәсе / техник хәл актлары пунктлары таләпләрен үтәү: | X |
| | | тулы күләмдә | 0 балл |
| | | 1 пункттан 3 пунктка кадәр үтәмәү | 3 балл |
| | | 3 пункттан 6 пунктка кадәр үтәмәү | 4 балл |
| | | тулы күләмдә үтәмәү | 5 балл |
| | | 1.1.4. Мәдәни мирас объектын, ачыкланган мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләнгән проект документларының, шул исәптән мәдәни мирас объектының, ачыкланган мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү турында эшләнгән бүлекнең булуы: | X |
| | | эшләнгән | 0 балл |
| | | юк | 2 балл |
| | | 1.1.5. Мәдәни мирас объектының (археологик мирас объектының) сакланышын тәэмин итү турында эшләнгән бүлек, коткару археологик кыр эшләрен үткәрү турында документлар яки әлеге мәдәни мирас объектының сакланышын тәэмин итү проекты йә коткару археологик кыр эшләрен үткәрү планы булу: | X |
| | | эшләнгән | 2 балл |
| | | юк | 1 балл |
| 1.2. | Мәдәни мирас объектларын, ачыкланган мәдәни мирас объектларын саклау, алардан файдалану һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәмәү ихтималын бәяләү | 1.2.1. Юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә соңгы 3 ел эчендә Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турындагы кодексында (алга таба – РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексы) түбәндәге статьялар буенча каралган административ хокук бозу кылган өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки индивидуаль эшмәкәргә административ җәза билгеләү турында закон көченә кергән карар булу: | X |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихый һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау турындагы законнар таләпләрен бозу» дигән 7.13 статьясы | 4 балл |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органның рөхсәтеннән башка җир, төзелеш яки башка эшләрне оештыру яки үткәрү» дигән 7.14 статьясы | 2 балл |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихый һәм мәдәни ядкәрләрен), тарихый җирлекне саклау предметын тәшкил итә торган объектларны (тарихый һәм мәдәни ядкәрләрне) юк итү яки җимерү» дигән 7.14.1 статьясы | 5 балл |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Мәдәни мирас объекты билгеләре булган объект ачыкланган очракта эшләрне яки мәдәни мирас объектының торышын начарайта яки аның бөтенлеген һәм сакланышын боза торган эшләрне туктату бурычын үтәмәү» дигән 7.14.2 статьясы | 2 балл |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы органның законлы күрсәтмәсен билгеләнгән вакытта | 2 балл |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | үтәмәү» дигән 19.5 статьясындагы 18 өлеше | |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Мәгълүмат бирмәү» дигән 19.7 статьясы | 1 балл |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Археологик кыр эшләрен рөхсәтсез үткәрү» дигән 7.15 статьясы | 3 балл |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Археологик предметларны законсыз әйләнештә йөртү» дигән 7.15.1 статьясы | 3 балл |
| | | РФ Административ хокук бозулар турындагы кодексының «Җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык яки башка эшләрне йә археологик кыр эшләрен рөхсәт кәгазе (ачык бит) нигезендә башкара торган башкаручының мондый эшләрне башкару нәтиҗәсендә табылган мәдәни кыйммәтләрне дәүләткә мәҗбүри тапшырудан читләшүе» дигән 7.33 статьясы | 1 балл |
| | | 1.2.2. Юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр эшчәнлеген риск категориясенә кертү турында карар кабул итү көненә үтәлмәгән күрсәтмә булу | 4 балл |